| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЗЕМЕЛЬНЫХ И<br>ИМУЩЕСТВЕННЫХ<br>ОТНОШЕНИЙ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ<br>МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

14.10.2025 Казан ш. № 3643-р

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 02.12.2022 № 3733-р боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт кадастр бәяләве турында» 2016 елның 03 июлендәге 237-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 21 статьяларына туры китереп, кадастр бәясен яңадан исәпләү турында «Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең 02.10.2025 № Р-16/2025/000042 карары нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләрен раслау турында” 02.12.2022 № 3733-р боерыгы белән (09.02.2024 № 283-р, 13.02.2025 № 439-р, 17.02.2025 № 475-р, 14.05.2025 № 1609-р, 01.09.2025 № 3057-р, 03.10.2025 № 3508-р боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләренә, күчемсез милек объектларының кыйммәтенә тәэсир итүче шартларның дөрес билгеләнмәгән булуы аркасында, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1599862 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1599862 | 16:50:250805:2 | 6 000,00 | 8 496,0076 | 50 976 045,60»; |

1619426 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1619426 | 16:50:140209:20 | 1 449,00 | 12 400,5020 | 17 968 327,40». |

2. Роскадастр гаммәви-хокукый компаниянең Татарстан Республикасы буенча филиалына күчемсез милек объектларының кадастр бәясе үзгәрүе турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрына тиешле тәртиптә үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының www.mzio.tatarstan.ru адреслы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.Ә.Кыямовка йөкләргә.

**Министр**
**Ф.Ә.Әһлиуллин**